| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

17.12.2020 — Казан ш. — № 547-7/тко-2020

«Әгерҗе муниципаль районы төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2021 – 2025 елларга чик дәрәҗә тарифлар билгеләү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Әгерҗе муниципаль районы төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә тарифларны билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән чик тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Әгерҗе муниципаль районы төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә шушы карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, 2021 – 2025 елларга чик дәрәҗә тарифларны җайга салуның дәвамлы параметрларын билгеләргә.

4. «Әгерҗе муниципаль районы төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 21 июнендәге 564 номерлы карары белән расланган Каты

коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 547-7/тко-2020
карарына 1 нче кушымта

«Әгерҗе муниципаль районы төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2021 – 2025 елларга календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/куб.метр | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 ел | | 2022 ел | | 2023 ел | | 2024 ел | | 2025 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | Әгерҗе муниципаль районы | | | | | | | | | | |
| 1 | «Әгерҗе муниципаль районы төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе | 107,08 | 118,35 | 118,35 | 191,50 | 155,15 | 155,15 | 155,15 | 163,30 | 163,30 | 163,54 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 547-7/тко-2020
карарына 2 нче кушымта

«Әгерже муниципаль районы төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2021 – 2025 елларга чик дәрәҗә тарифларны җайга салуның дәвамлы параметрлары

| № п/п | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Әгерже муниципаль районы төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе | | | | | |
| 1.1 | Каты коммуналь калдыкларны күмү | 2021 | 7100,15 | 1 | 0 | 0,22 |
| | | 2022 | x | 1 | 0 | 0,22 |
| | | 2023 | x | 1 | 0 | 0,22 |
| | | 2024 | x | 1 | 0 | 0,22 |
| | | 2025 | x | 1 | 0 | 0,22 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге